Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XI-9**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 15 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләр тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы тәкъдимен кабул итәргә:

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханәләренең китапханә фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

- буш вакытны оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

-җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуны күздә тотып, типовой рәвештәге кушымта нигезендә тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2016 елның 15 июлендәге
XI-9 номерлы карарына

кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турында**

**КИЛЕШҮ**

Балык Бистәсе штп. «___»_____, 2016 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә таянып эш итүче үзенең җитәкчесе ________________ йөзендә, алга таба “район Башкарма комитеты” дип аталучы бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче үзенең җитәкчесе ________________йөзендә, алга таба “җирлек Башкарма комитеты” дип аталучы икенче яктан, бергә “Яклар” дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1.Килешү предметы

Әлеге Килешүнең предметы булып җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан район Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру тора:

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханәләренең китапханә фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

- буш вакытны оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

-җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары (алга таба - вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләр үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны әлеге Килешүнең 4.1-4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә тикшереп торырга;

Әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны район Башкарма комитетыннан алырга.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен җирлек Башкарма комитетына, шулай ук аерым гарызнамәләр буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Район Башкарма комитеты хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

җирлек Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә рәвештә файдалану.

**3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе**

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бюджет законнары нигезендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме елына ____________________ сум күләмендә билгеләнә.

3.3.Район Башкарма комитеты финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

**4. Вәкаләтләрне үтәүне тикшереп тору**

4.1. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында район Башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүмат соратып ала. Район Башкарма комитеты авыл җирлеге Башкарма комитеты сораткан мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга кереп йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс чараларын тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча гамәлгә ашырыла.

**5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

5.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.3. Якларның берсе дә әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча аның өзелүе турында белдермәсә, Килешү 2017 елга озайтылган дип санала.

**6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе**

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

6.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче Якка язма рәвештә, аның гамәлдә булу датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын җирлек Башкарма комитетына кире кайтара.

**7. Якларның җаваплылыгы**

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф сала.

7.3. Штраф түләү Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны алга таба үтәүдән азат итми.

**8 маддә. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

8.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәс сөйләшүләр уздыру яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителмәгән очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара килешүе буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язмача рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр бу килешүнең аерылгысыз өлеше.

9.2. Килешү ике якның һәрберсе өчен берәр юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

**10. Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе<br>______________ ____________ | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе<br>______________________________ |